ФАРАЗ ҺӘМ ӨМЕТ
«ВТ» хәбәрчесенең ил-көн вакыйгаларына карашы
> 2

КЫР БАТЫРЛАРЫ
«Урып-җыю җитүгә, йөрәк ешрак тибә башлый, күңел кырга ашкына»
> 3

ӘНИЛЕ ТОРМЫШ
Әминә әбинең авылда чын исемен белмиләр дә
> 3

ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – монда
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 149 (29116) | Чәршәмбе | 11 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КЫЙММӘТЛЕ ҖЫЛЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Көн кадагында

Җылытты! Дөресрәге, урамда суытты, өйләрдә торбалар кайнарлана башлады. Тик җылылык бирү сезоны килеп җитү бер яктан сөендерсә, икенче яктан көендерә: коммуналь хезмәтләр өчен түләү арта. Кайберәүләргә акчаны җылылык биргәнче үк исәпләгәннәр әнә. Быел ТКХ өчен түләүдә үзгәреш бармы? Яңа елдан соң тарифларны ни көтә? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга ачыклык кертте.

Сентябрь ае бик матур килү сәбәпле, быел җылылык бирү сезоны бераз соңарды. Республика күләмендә барлык йортларга да узган атнада җылы бирә башладылар. Хәер, балалар бакчасы, мәктәп, хастаханә кебек социаль объектларны салкыннар башланганны көтеп тә тормыйча, сентябрь азагында ук җылыта башладылар инде. Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, бу атна башында республикадагы барлык балалар бакчаларының – 96, мәктәпләр һәм хастаханәләрнең 93 процентына җылы биргәннәр.

Торбалар кайнарланганны көн саен сагалап торсак, җылылыкка түләү кайберәүләр өчен көтелмәгән хәл булып чыкты. Бу арада социаль челтәрләрдә Казанның кайбер урамнарында яшәүчеләр сезон башланмаган килеш, сентябрь счет-фактурасында әлеге төр хезмәт өчен түләү килгәннән зарлана. Әйтүләренә караганда, фатирның мәйданына карап, салкын торба өчен уртача 2–4 мең сум акча түләргә язганнар.

– Гомуми йорт исәпләгече кую өчен техник мөмкинлекләр булмаган йортларда яшәүчеләр исәп-хисапны, җылылык бирү сезоны кайчан башлануга да карамастан, сигез айга бүлеп исәпләнгән норматив буенча түли. Бу нигездә иске – күбесе авария хәлендәге ике, өч катлы йортларда яшәүчеләргә кагыла. Анда исәпләгечләр урнаштыру өчен коммуникация юк, – дип мәсьәләгә ачыклык кертте «Татарстанның ТКХ өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге» башкарма директоры Дмитрий Романов. – Шуңа күрә мондый йортларда яшәүчеләрдән сентябрь аенда җылылык өчен акча түләтүләре канунга туры килә. Гади халык моны аңлап кына бетерә алмый. Чынлап торып исәпләп карасаң, җылылык өчен норматив буенча исәп-хисап ясаучылар, исәпләгеч буенча түләүчеләргә караганда, азрак та түли әле. Һәрхәлдә, күбрәк түгел.

Дмитрий Романов әйтүенчә, әгәр норматив буенча артык күп акча исәпләгәннәр дип шикләнәсез икән, идарәче компаниягә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Алар гади халыкны кызыксындырган барлык сорауларга ачыклык кертергә тиеш.

Билгеле булганча, соңгы тапкыр коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр ил күләмендә узган елның 1 декабрендә артты. Ут-су, җылылыкка бәяләр гадәттә елга бер тапкыр җәй көне үсә. Россия Хөкүмәте карары нигезендә исә былтыр тарифлар бер ел эчендә ике тапкыр күтәрелде. Алдагы ел белән чагыштырганда, республиканың кайбер шәһәр һәм районнарында яшәүчеләрнең ут һәм суга киткән чыгымнары 20 процентка кадәр артты. Алга таба коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 2024 елның җәендә генә артачак. Шулай итеп, ел ярым дәвамында кыйммәтләнмәячәк. Шулай дип ышандыралар.

> Бәяләргә аерым тукталыйк. Республикада яшәүчеләр өчен электр энергиясенең бәясе, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алып, бер кВт/сәгате 4 сум 68 тиен тәшкил итә. Электр плитәләре яки электр җылыту җайланмалары булган йортларда яшәүчеләр өчен бер кВт/сәгате – 3 сум 58 тиен, ә авылда яшәүчеләр өчен – 3 сум 28 тиен. Газның бер куб метры – 6 сум 78 тиен. Су өчен тариф кайсы оешма хезмәт күрсәтүенә карап аерыла. Әйтик, Түбән Кама халкына суның бер куб метры – 32 сум 10 тиен, ә пычрак суны агызуның бер куб метры 21 сум 76 тиен тора. Каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен күпфатирлы йортларда яшәүчеләр аена бер кеше өчен – 103 сум 93 тиен, шәхси торак йортларда яшәүчеләр исә 112 сум 74 тиен түли.

Киләсе елда тарифлар күпмегә артачак? Әлегә бу сораура төгәл җавап юк. Илнең социаль-икътисадый үсеш фаразларына караганда, 2024 елда коммуналь хезмәтләр өчен түләү 9,8 процентка артырга мөмкин. Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетыннан хәбәр итүләренчә, төгәл саннар ел азагына кадәр билгеле булачак.

Акчаны янга калдыру юлы бар анысы. Ул да булса – коммуналь түләүләргә субсидия рәсмиләштерү, ягъни түләгән акчаның бер өлешен кире кайтару. Республикада халыкка ярдәм итү максатыннан ташлама-субсидияләр бирү каралган. Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, мондый ярдәмгә социаль нормалар һәм нормативларны исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 21 процентыннан артып киткән гаиләләр өмет итә ала.

Ахыры 2 нче биттә >

Эш табылыр

2030 елга илдә бигрәк тә авыл хуҗалыгында (300 мең кешегә), сәүдә (200 мең), финанс һәм иминиятләштерү (100 мең), шулай ук күчемсез милек өлкәсендә белгечләргә (100 мең кешегә) ихтыяҗ кимеячәк. Россия Икътисадый үсеш министрлыгы шундый фараз корган.

Министрлыкта билгеләп үтелгәнчә, хезмәт базарына илдәге икътисадый вазгыять, демография, цифрлаштыру, автоматлаштыру, тармакларны үзгәртеп кору йогынты ясый. Фараз корганда, боларның барысы да исәпкә алынган. Кыенлыкларны исәпкә алып, «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проектын 2030 елга кадәр озайту тәкъдим ителгән.

Әмма башка фикер әйтүчеләр дә бар. Әйтик, Хөкүмәт каршындагы Финанс университеты профессоры Александр Сафонов билгеләп үткәнчә, авыл хуҗалыгында эшче кулларга ихтыяҗ кимемәячәк. Хәтта автоматлаштыру кертелгән очракта да, 2030 елга кадәр һәм аннан соң зур үзгәрешләр булмаячак. «Авыл хуҗалыгында продукция җитештерү күләме артса, хезмәткәрләргә дә ихтыяҗ үсәчәк. Тармактан байтак кешенең махсус хәрби операциягә китүе дә моңа йогынты ясаячак», – дигән белгеч.

Тыелу коткарачак

Киләсе елның 1 июленнән үз исемеңә кредит алуны тыярга мөмкин булачак. Дәүләт Думасы шундый закон проектын беренче укылышта хуплаган. Ул халыкны мошенниклардан сакларга тиеш.

Дума Рәисе Вячеслав Володин әйтүенчә, депутатлар проектны бик күп мөрәҗәгатьләргә җавап йөзеннән әзерләгән. «Халык бу карарны көтә. Закон кешеләрне, шәхси мәгълүматларын урлап, кредит рәсмиләштерүче мошенниклардан саклау мөмкинлеге бирәчәк», – дигән ул.

Володин аңлатып үткәнчә, һәрбер кеше үз исеменә теләсә нинди кредит алуны тыя алачак. Банкларның гына түгел, микрофинанс оешмаларының акчасына да кагыла бу. Ә инде кредитның кирәге чыкса, тыюны гамәлдән чыгарырга мөмкин булачак.

Моның өчен Күпфункцияле үзәккә яки Дәүләт хезмәтләре порталы аша тиешле гариза язып тапшыру күздә тотыла (СНИЛС номерын күрсәтү таләп ителәчәк). Кредит кирәк икән, тагын бер гариза тапшырып, 1 көн эчендә тыюны гамәлдән чыгарырга мөмкин булачак.

Бушлай кишәрлек

Казанда исәпкә куелган күпбалалы гаиләләрнең 39 проценты бушлай җир кишәрлекләре белән тәэмин ителгән. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматларына караганда, Татарстан буенча бу күрсәткеч 65,34% тәшкил итә.

Бүгенгә республикада барлыгы 72533 күпбалалы гаилә бушлай җир алуга документлар тапшырган. 71843 гаиләне исемлеккә кертү буенча карар кабул ителгән.

Җәмгысы 46611 җир кишәрлеге бирелгән. Шуның 7063е – Казанда.

Баланы да аямый

Татарстанда күз авыруларыннан тилмергән балалар саны арткан. Узган ел табибларга шундый гозер белән 16 мең бала мөрәҗәгать иткән. Алар күбрәк ерактан начар күрү яки әйберләрне аермачык күрмәүдән (астигматизм) интегә икән. Бу хакта журналистларга Республика клиник офтальмология хастаханәсе баш табибы урынбасары Елена Жиденко хәбәр итте.

Хәзерге вакытта республикада 101 мең кеше күз авырулары белән исәптә тора. Елена Жиденко сүзләренә караганда, соңгы арада балалар арасында күз ялкынсыну очраклары да ешрак очрый башлаган. «Хәзерге балалар бөтенләй башкача укый. Шул ук компьютер, гаджетларны да актив кулланалар. Алар аркасында күзләргә авырлык килә», – ди табиб.

shutterstock.com

Нәтиҗә

Ашаган белми, түләгән белә

Көзге шыксыз көндә Хөкүмәт йортында эссе җәйгә йомгак ясадылар. Төгәлрәк әйтсәк, лагерьларда ял иткән Татарстан балаларын санадылар. Быелгы җәй хәвеф-хәтәрсез узып китте китүен, ә балалар һәм әти-әниләр канәгать калганмы? Лагерьлар саны арта, начар хәлдәгеләре төзекләндерелә, ә ял итүче балалар саны ни сәбәпле кими?

> **Балаларның җәйге ялы – саннарда:**
> ✓1554 лагерьда җәмгысы 148704 бала ял иткән;
> ✓балалар ялы өчен 2331,9 млн сум акча тотылган (узган елгыдан 330,94 млн сумга күбрәк). Шуларның 203,5 млн сумы – әти-әниләр акчасы;
> ✓38046 кешегә бушлай юллама бирелгән;
> ✓4937 бала – Кара диңгез буенда, 3797 бала – Краснодар краенда, 1140 бала Кырым Республикасында ял иткән.

Бу һәм башка сорауларга Министрлар Кабинетында узган брифингта җавап эзләдек. Татарстанның яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков сүзен санлы күрсәткечләрдән башлады.

– Быелгы җәйге каникулда 148704 бала сәламәтләндерү лагерьларында ял итте. Шул рәвешле планның 91 проценты үтәлде. Балаларны 131 шәһәр яны, 46 палаткалы лагерь кабул итте, шулай ук Мәгариф министрлыгы линиясе буенча 68 меңләп бала җәен 1377 көндезге, ял һәм хезмәт лагерьларында уздырды, – дип сөйләде ул.

Сүз уңаеннан, 2022 елда җәйге лагерьлар 154 мең баланы кабул иткән. Быел бу сан кимрәк. Сәбәбен министрдан сорадык.

– Җәйге ялын лагерьда уздырырга теләүчеләр саны елдан-ел арта гына. Ә быел ял итүчеләр санының кимрәк булуы 13 лагерьда капиталь ремонт эшләре баруына бәйле. Икенче елга ул лагерьларны эшләп бетерәбез, балалар саны да артыр, – дип җавап бирде ул.

Быел Татарстанда җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә җәмгысы 2,3 млрд сум акча тотылган. Узган ел исә бу сумма 19 процентка кимрәк булган.

– Финанслау 330 млн сумга артты. Бу исә туклануны оештыру, медицина хезмәте күрсәтү, канцтоварлар, мәдәни программа һәм коммуналь хезмәтләр өчен чыгымнар артуга бәйле, – дип аңлатты Садыйков.

Тагын бераз санлы мәгълүмат. Быел республика лагерьларында Луганск һәм Донецк халык республикаларыннан килгән 745 бала өчен бушлай сменалар оештырылган.

– Хәзерге вакытта Лисичанск һәм Рубежныйдан килгән 187 бала өчен тагын бер смена уза. Ул 22 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк, – диде яшьләр эшләре министры.

Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Әсадуллина быелгы яңалыклар белән таныштырды.

– Елдагыча, без авыр тормыш хәлендә калган гаиләләрдә тәрбияләнүче, тәрбиягә алынган, сәламәтлеге какшаган балалар, төрле бәйгеләрдә, олимпиадаларда актив катнашучы сәләтле укучылар өчен сменалар оештырабыз. Безгә интернат мәктәпләрдә сәламәтлекләре чикле балалар өчен мәктәп яны лагерьлары оештыруны сорап мөрәҗәгать итүчеләр күп иде. Быел без Арча, Әлмәт, Лаеш районнарында 120 бала өчен шундый сменалар да оештырдык, – диде ул.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:

Илдән киткән һәм Киевның канкойгыч нацист режимына җиңү теләп, аларның Россия территориясенә атканына сөенеп, кабахәт гамәл кылган кешеләр шуны аңларга тиеш: монда аларны беркем дә көтми. Инде кайталар икән, Магаданга туры юл көтә.

РОССИЯДӘ – «СОЦИАЛЬ КИШТӘЛӘР»

SuperJob хезмәте уздырган сораштыруда катнашучыларның күпчелеге пенсионерлар һәм аз керемлеләр өчен кибетләрдә «социаль киштәләр» оештыруны хуплаган. Мондый киштәләргә вакыты чыккан товарларны куеп, бушлай бирү яки арзан бәядән сату күз уңында тотыла.

«СОЦИАЛЬ КИШТӘЛӘР»НЕ ХУПЛЫЙСЫЗМЫ?

Җавап	Барлык катнашучылар	Җенес		Айлык керем		
		Ир-ат	Хатын-кыз	49999 сумга кадәр	50000–79999	80000 сумнан
Әйе	71%	68%	75%	70%	75%	67%
Юк	17%	20%	13%	17%	14%	22%
Икеләнәм	12%	12%	12%	13%	11%	11%



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

УТСЫЗ-СУСЫЗ ГАЗЗӘ

Фәләстыйн фаҗигасе дөньякүләм мәгълүмат чараларында төп тема булып калуын дәвам итә. Израиль Хөкүмәте Газзә секторын тулы блокадага алды: утны өзде, су торбалары бикләнде. Сүз 360 квадрат километрлы мәйданда 2 миллионнан артык кеше яшәгән төбәк турында бара. Чагыштыру өчен: Арча районы 1842 квадрат километрны били, ягъни Газзәдән 5,11 тапкыр зуррак.

Халык тыгыз яшәгән төбәкне бертуктаусыз күктән бомбага тоту, торак йортларны җимерү нинди нәтиҗәләргә китерүен күз алдына китерегез. Сабый балалар газаплы үлем белән үлә, хатын-кызлар һәм картлар гарип кала. Шул ук вакытта Израиль һәм дөнья матбугаты фәләстыйнлыларны хатын-кызларны үтерүдә һәм балаларны әсирлеккә алуда гаепли, ерткычлар һәм хайваннар дип бәяли. Расачалыкның бу дәрәҗәсе бүгенге дөньяда башка бер илдә дә күзәтелми. Бары тик Израильгә генә дошманнардан вәхшиләрчә үч алу хокукы бирелгән. Искә төшерик: әле генә Азәрбайҗан үз төбәге булып саналган Карабахны минималь кан коюлар белән азат итте, тыныч халыкның иминлеген йөз процентка тәэмин итәргә тырышты. Шуңа карамастан Көнбатыш илләре Бакуга каршы пропаганда алып барды, кешелексезлектә гаепләргә омтылды. Санкцияләр кертергә азапландылар. Миллионлаган гарәпне йортларыннан куып, үтереп, төрмәләргә ябып, җитмеш елдан артык вәхши сәясәт алып барган Израильгә карата беркем дә санкцияләр кертми.

Гарәпләрне ерткычлар итеп күрсәтү өчен, күпсанлы фейклар таратыла. Бу рәсми дәрәҗәдә оештырыла. Әйтик, читлеккә ябылган балалар төшерелгән видеоролик актив таратыла. Янәсе ХАМАС сугышчылары тотак итеп алынган сабыйларны шулай газаплый. Чынлыкта видео 2015 елда ук төшерелгән һәм анда Сүрия балаларының авыр язмышы чагыла. Дөрес мәгълүмат тарату кыен. «Ютуб» фәләстыйнлыларны яклаган блогерларны бикли. Башка мәгълүмат чараларында хәл шуннан яхшы түгел. Шуңа карамастан АКШта һәм дөньяның башка илләрендә Фәләстыйнны яклап урамга чыгучылар аз түгел.

Вашингтон штатындагы Киркленд шәһәрендә Фәләстыйнны яклаучылар белән Израильне яклаучылар арасындагы бәрелешне полиция ярдәмендә туктатырга туры килгән. Шунысы игътибарга лаек: сиончылар кансызлыгын гыйбриләрнең барысы да якламый. Ортодоксаль яһүдләр – хареди гыйбриләре «яһүдлек ул – сиончылык түгел, Израиль гыйбриләрне гәүдәләндерми» дип белдерделәр һәм Израиль флагларын яндырдылар. Human Rights Watch халыкара хокук яклаучылар оешмасы Израиль гамәлләрен хәрби җинаять дип бәяләде. Россия хакерлары төркеме Killnet Израильне кан коюда гаепләде. Европаның 4 иле – Испания, Дания, Люксембург, Ирландия Евросоюзның Фәләстыйнга финанс ярдәмен туктату турындагы карарына каршы чыкты, аны үткәрмәде.

Россиядә

ДОЛЛАР КӨЗГЕСЕ

Доллар – сум атынгычы тирбәлеп тора. Дүшәмбедә аның бәясе 103 сумнан югарырак күтәрелеп алды, ләкин кичкә кадәр сум берникадәр ныгып, үз позицияләрен кайтарды. Үзәк банк барлы-юклы резервларын кырып-себереп базарга чыгарды, диделәр. Сишәмбе иртәсендә, бу юллар язылганда, доллар яңадан йөз сумнан югарырак бәягә күтәрелде.

Тотрыксызлык Үзәк банкны кыен хәлгә куя. Төп ставканы күтәрү кебек популяр булмаган гамәл дә булышмады. Тагын да кискенрәк чаралар күрү мөмкин, әмма Үзәк банк рәсми рәвештә белдерә: файдасы вакытлыча гына булачак. Финанс белгечләре яңа хәвеф сызыгы сызды: доллар 110 сумнан артса, киеренкелек ноктасын үтәчәк. Валюта курсларына игътибар итми дә яшәп була, әмма барыбер кесәләргә бәреп керә ул. Инфляция доллар курсы белән тыгыз бәйләнгән, ике-өч айга соңгарак калып кайтаваз бирә. Доллар кыйммәтләнүенең бердәнбер уңай ягы: бюджет көпшәкләнгән сумнар белән тула. Ләкин кыйммәте кимегән сумның күп булуы аз булышачак. Хезмәт хакларының доллардагы күләме киму тормышның матди ягын кыенлаштырмый калмый. Бюджетта эшләүчеләр хәле көннән-көн яманлана.

Укытучыларның хезмәт хакы казнадан акча алучылар хәлен яхшы чагылдыра. «Укытучы» профсоюзы төбәк хөкүмәтләренең мөгаллимнәргә билгеләгән хезмәт хакына мониторинг үткәргән. Нәтиҗәләр мондый: ил төбәкләренең 40 процентында белем бирүчеләрнең оклады минималь хезмәт хакының яртысыннан артмый. 3420дән 9580 сумга кадәр. Төбәкләрнең тагын 39 процентында оклад минималь хезмәт хакының 50–75 проценты кадәр. Курск өлкәсендәге 9668 сумнан Томск өлкәсендәге 14091 сумга кадәр. Төбәкләрнең 9 процентында укытучы оклады иң түбән хезмәт хакының 75 процентыннан 100 процентка кадәр. Ростов өлкәсендә – 14449 сум, Татарстанда – 16157. Ямал-Ненец автоном округы, Магадан өлкәсе һәм Приморьеда гына окладлар минималь түбән хезмәт хакы күләменнән артык. Окладларны доллар курсына бүлегез әле. Иң яхшы окладлы Татарстанда – 160 доллар тирәсе. Доллар үсүен дәвам итмәгән очракта әле бу. Укытучылар окладка гына эшләми, әлбәттә. Шәһәрләрдә ике һәм аннан артык окладка эшләү – гадәти хәл. Аз комплектлы авыл мәктәпләрендә бер окладны тотыру да кыен.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ИСКЕ ЯҢАНЫ САКЛЫЙ

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов Нурсолтан Назарбаев урамында төзекләндерелгән күперне ачу тантанасында катнашты. Моңа кадәр биредә 6 юл полосасы булса, хәзер аларның саны 8гә җитте. Җәяүлеләргә дә йөрү уңайлырак булачак. Күпернең озынлыгы 436,5 метр тәшкил итә.

Шәһәр өчен мөһим корылмаларга яңа сулыш өреләчәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казанның тарихи үзәгендә кайбер корылмаларны карап-барлап чыкты.

Моңа кадәр ЦУМ урнашкан бинада Халык-сәнгать һөнәрләре һәм осталар үзәге ачарга ниятлиләр. Биредә остаханәләр, җитештерү мәйданнары, осталык дәресләре уздыру өчен махсус урыннар булыр дип көтелә. Якын арада төзүчеләр эшкә тотыначак. «Иң мөһиме – бу урын кешеләрне тартып торучы үзәк булырга тиеш», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Бишбалта бистәсендә урнашкан янгын сүндерү депосы XX гасырның 30 нчы елларындагы архитектура корылмасы санала. Соңгы елларда Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы карамагында булган. Авария хәлендә, дип табылуы сәбәпле сүтелергә тиеш булган. Җәмәгатьчелек бинаны саклап калуны сорагач, Татарстан Рәисе ярдәмендә аны 2016 елда консервацияләү турында карар чыгардылар. Казан башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты биредә яшьләр үзәге ясарга тәкъдим итә. Биредә булачак конструкторлар һәм инженерлар әзерләү өчен техник юнәлештәге дәресләр оештырырга ниятлиләр. Рөстәм Миңнеханов, тәкъдимне хуплап, бинаның төзеклеген тикшерергә кушты. Татарстан Рәисенә Янгын сүндерү депосы янәшәсендә яңартылган Балыкчы бакчасында башкарылган эшләр турында да сөйләделәр.

Рөстәм Миңнеханов Гаяз Исхакый урамында XVIII гасырда төзелгән торак йортны да барып күрде. Бу бина мәдәни мирас объекты булып санала. Хәзер аның 30 проценты гына сакланып калган. Архитектор-реставратор Альбина Хәйруллина Татарстан Рәисенә корылманы кабат сафка бастыру һәм аннан файдалану юлларын тәкъдим итте.

Татарстан Рәисе Юныс мәйданын төзекләндерү нәтиҗәләре белән дә танышты. Бу мәйданчык XVIII гасырның икенче яртысында булдырылган. XX гасыр башларында 4 бакчаны берләштерүче сквер-мәйданга әйләнгән. Төзекләндерү 2020 елда башланды. Биредә яктырткычлар урнаштырылган, җәяүлеләр сукмаклары төзекләндерелгән, татар йортының эчке күренешен чагылдыручы әйберләр – сандыклар, эскәмияләр урнаштырылган.

Юныс мәйданыннан соң Рөстәм Миңнеханов 1905 елда төзелгән Александров-Петцольдның сыр кайнату заводы комплексына тукталды. Завод биналары мәдәни мирас объектлары, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башының сәнәгать архитектурасы үрнәге булып тора. Петцольд заводын яңарту планында галереялар, татар милли ашлары рестораны, офислар, кунакханәләр булдыру күздә тотыла. Татарстан Рәисенә Түбән Кабан күле һәм Камал театрының яңа бинасы тирәсендәге урыннарны төзекләндерү турында да сөйләделәр.

Ахырдан Рөстәм Миңнеханов Горький паркында булды. Биредә парк капкасын реконструкцияләү эшләре алып барыла. Шунда ук Рәискә «Аэромост» аркан юлы проектын тәкъдим иттеләр. Ул 3 станциядән: Горький паркы, «Урам» экстрим-паркы һәм «Ак Барс Арена» стадионы станцияләреннән торачак.

Дәүләт Советында

ЭШЛӘП КҮРСӘТӘСЕ

Депутатлар альтернатив хезмәтне оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләрендә узарга тәкъдим итә.

Парламентның Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында закон проектын комитет рәисе урынбасары Александр Чубаров тәкъдим итте. Документны Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов белән берлектә әзерләгәннәр.

Эш шунда ки, хәзерге вакытта оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре альтернатив хезмәт узу мөмкинлеге булган оешмалар категориясенә керми.

– Предприятиеләрдә дәүләт-оборона заказлары артты. Алар яшь белгечләрне эшкә алырга, аларны өйрәтергә әзер. Тик яшьләр арасында мондый һөнәрләр абруйлы түгел. Шуңа күрә заводка эшкә ашыкмыйлар. Мәсьәләне хәл итү юлы буларак, альтернатив хезмәтне оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләрендә дә узарга тәкъдим итәбез, – диде депутат.

Моннан тыш, заводтагы хезмәткәрләр санын саклап калу өчен хәрби хезмәткә чакырудан бер елга кадәр кичектерү тәкъдиме дә бар. Сүз вуз, көллият, техникум тәмамлап, оборона-сәнәгать комплексы предприятиесенә тулы эш көненә эшкә урнашучылар турында бара. Шул ук вакытта, хәрби хезмәткә баруны кичектереп тору мөмкинлеген тәэмин итүче оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре, һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре исемлеге ил Хөкүмәте тарафыннан расланачак.

– Бүген армиягә чакырылучылар белән чагыштырганда, альтернатив хезмәт узучылар саны алай ук күп түгел. Шуңа күрә алга таба яшьләр дәррәү кубып икенче юлдан китәчәк дип уйламыйбыз, – дип тә өстәде Александр Чубаров.

Комитет вәкилләре закон проектын хуплады. Аны Дәүләт Советының чираттагы утырышында карап тикшерерләр дип көтелә.

КЫЙММӘТЛЕ ҖЫЛЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Субсидия рәсмиләштерү өчен яшәү урыны буенча социаль яклау бүлекчәләренә мөрәҗәгать итәргә яки Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза җибәрергә кирәк. Субсидия ярты елга билгеләнә, аннары яңадан документлар тапшырырга кирәк. Акчалата ярдәмгә муниципаль яки дәүләт торагында яшәүчеләр, наем килешүе нигезендә фатир алып торучылар, торак кооперативы әгъзалары, фатир, шәхси йорт хуҗалары дәгъва кыла ала. Тагын бер шарт – торакның мәйданы. Ул билгеләнгән стандартларга туры килергә тиеш. Әлеге күрсәткечне һәр төбәк үзе билгели. Татарстанда ул бер кешегә – 40 квадрат метр, ике кешелек гаиләдә җан башына – 23 квадрат метр, өч кешелек гаиләдә исә 17 квадрат метр тәшкил итә. Дәүләттән акчалата ярдәм алганчы, керемнәрне раслап күрсәтергә туры киләчәк. Шуны истә тотыгыз: коммуналь түләүләр буенча бурычлары булганнарга субсидия бирелми.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Елена БОНДАРЕНКО, «Иҗтимагый фикер – Татарстан» фонды директоры урынбасары:

– Коммуналь хезмәтләр өчен түләү елдан-ел көнүзәк мәсьәләгә әверелеп бара. Сәбәбе дә билгеле. Бу халыкның керем дәрәҗәсенә бәйле. Без утсыз да, сусыз да, җылылыктан башка да яши алмыйбыз. Димәк, әлеге төр хезмәтләр өчен түләү, ашауэчү һәм дәвалану белән беррәттән, гаиләнең мәҗбүри чыгымнарын тәшкил итә. Ни кызганыч, инфляция аркасында илдә яшәүчеләрнең кереме кими. Шунысы да бар: еш кына ТКХ сыйфаты халыкта ризасызлык уята. Чүп чыгаруга бәйле проблемалар турында еш ишетәбез. Кыш көне Казанны кар көртләре баса яки шәһәр үзәгендә туристлар, егылып, аяк-кулларын сындыралар. Ел башыннан бирле Татарстан башкаласына 3 миллионга якын турист килгән, дип горурланып сөйлибез югыйсә. Җылылык бирү сезонына килгәндә, быел ул әйбәт кенә башланып китте, өйдә озак туңып утырырга туры килмәде. Булганның кадерен бик үк белмибез, дигән фикер дә бар. Россияне башка илләр белән чагыштырып караганда, Көнбатыш илләрендә, мәсәлән, шул ук җылылык өчен аена 300–400 доллар акча түлиләр. Әле ул очракта да торбаларны иртән бер сәгатькә – урыннан торып китү өчен, кич ике сәгатькә – ашап-эчеп йокларга яту өчен генә кабызып алалар. Шуңа күрә һәр ике якка да бер-береңне хөрмәт итә белергә кирәк.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Низаметдинов** Ралиф Хәниф улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

АШАГАН БЕЛМИ, ТҮЛӘГӘН БЕЛӘ

vk.com

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Әйләнә дә килә җәйләр...

Елдагыча, лагерьлар турындагы сөйләшүдә юллама бәяләре дә телгә алынды. Яшьләр эшләре министрлыгы тәкъдим иткән 2023 ел бәяләрен таблицадан күреп була.

– Республика лагерьларына юлламалар бәясе узган елгыдан артмады диярлек. Коммерцияле лагерьларга килгәндә, алар бәяне үзләре билгели. Шуңа да алар өчен җавап тота алмыйбыз, – диде Ринат Садыйков.

Юлламаларга бәяләр артмаса да, елның-елында әти-әниләр кесәсенә суга торган проблема булып кала бирә ул. Хезмәттәшебез Эльвира Вәлиева да шулай ди.

– Улым спорт мәктәбенә йөри, шуңа күрә безгә балалар лагерена бару, кем әйтмешли, ихтыяри-мәҗбүри. Былтыр җәй көне Яшел Үзәндәге «Мирас» лагерена бардык, бәясе 22 мең сум иде. Каникул саен баланы бу бәягә лагерьга җибәрү кесәгә суга, гаиләдә ике-өч бала тәрбияләүчеләр дә бар бит әле. Шуңа күрә быел арзанлырак лагерь сайладык. Язгы каникулда да, җәй көне дә Биектаудагы «Молодежный» лагерена бардык. Бәясе – 12 мең сум, өстәмә чыгымнар белән 18 мең сумга төште. Сыйфаты бәясенә күрә димәс идем, балаларга биредә күбрәк ошый. Көзге каникулда да шул лагерьга барачаклар. Тик шунысы бар: бәясе арзанрак булган лагерьга эләгү бик авыр, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

2023 ЕЛНЫҢ ҖӘЕНДӘ ЛАГЕРЬЛАРГА ЮЛЛАМА БӘЯЛӘРЕ (уртача)

Профильле программалары һәм тематик юнәлеше булган лагерьда 18 көнлек смена	18172 сум
Бюджет оешмаларында эшләүчеләрнең балалары өчен 21 көнлек смена	18397 сум
Чатырлы лагерьда 7 көнлек смена	7397 сум
Коммерцияле лагерьда 18 көнлек смена	24572 сум

СЫНАЛДЫК – СЫНАТМАДЫК

Илнар Сөләйманов

Евгений һәм Марсель Үтәгановлар, Рөстәм Абзалов

Ания Сафина

Илдар Мөхәммәтҗанов

Узган якшәмбедә республикада Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре көнен билгеләп үттеләр. Мөслим районында «Туган як» агрофирмасы да игенчеләрен һәм терлекчеләрен, гомумән, табыныбызны мул ризыклы итәр өчен үз көчләрен кызганмый эшләгән тырыш хезмәт кешеләрен бәйрәмгә җыйды.

Алар арасында кыр батыры Илнар Сөләйманов та бар иде. Ул быелгы урып-җыюда 39 мең центнер ашлык җыеп алуга ирешкән. «Туган як» агрофирмасында эшләвенә дә 20 елга якын икән инде.

– Әтием дә гомер буе колхозда эшләгән. Кечкенәдән үк аның хезмәтен күреп үскәнгә, шәһәргә китү, кайсыдыр башка өлкәне сайлау турында уйлаганым да булмады. Авылның саф һавасы, табигате һәм тыныч булуы ошый миңа, – ди ул.

Алдынгы комбайнчы әйтүенчә, мул уңыш җыеп алу өчен тырышлык һәм табигать шартларының уңай килүе кирәк.

– Болардан тыш, эшкә тотынганчы техниканы карап-әзерләп куя белү дә, җитәкчелекнең запас частьлар белән вакытында тәэмин итүе дә һәм, әлбәттә инде, уңыш елмаю да кирәк. Һәр ел үзенчәлекле. Быел урып-җыюга иртә керештек, эшләрне дә иртә тәмамладык. Ел коры булганлыктан, уңыш узган елга караганда азрак булды, әмма булганының бөртеген дә сарыф итмичә җыеп алу мөмкинлеге туды. Соңгы елларда авыл халкының үзәгенә үткән иң зур проблема – корылык. Халыкка да, авыл хуҗалыгына да йогынтысы зур аның. Мондый коры елларда әйбәт уңыш алуда җирне сыйфатлы итеп эшкәртү, корылыкка чыдам орлыклар утырту, корткычларга каршы чаралар куллану, яфрактан тукландыру һәм ашламалар кертү зур роль уйный, – ди Илнар Сөләйманов.

Агрофирмада механизаторлар династиясе дә хезмәт куя. Евгений Үтәганов – теләсә нинди авыл хуҗалыгы техникасын иярли. Кирәк икән, комбайн штурвалын тота, кирәк икән, теләсә нинди заманча тракторга утыра.

– Әтиебез дә гомер буе механизатор булып эшләде. Балалар бакчасыннан бирле аның янәшәсендә йөрүемне хәтерлим. Җир эшен яратканга бу тармакта 16 ел эшлим, – диде Евгений.

Бертуган энесе Марсель да абыйсы юлыннан киткән. Баштарак Евгенийның комбайнчы ярдәмчесе булып йөргән дә 2018 елда үзе дә мөстәкыйль эшли башлаган.

– Комбайнда да, тракторда да йөрим, ләкин соңгысында эшләү күбрәк ошый. Язын – чәчүдә, җәен – урып-җыюда, көзен җир эшкәртәм. Эшемне ятаркач, авырлыгын сизмим дә, – дип елмайды Марсель.

Егетләрнең икетуганнары Рөстәм Абзалов та шушы ук агрофирмада хезмәт куя.

– Мин моңарчы җиде ел «Агромастер» агрофирмасында комбайн йөрттем. Ә бире дә эшли башлавым очраклы рәвештә генә килеп чыкты. Абыем бер көнгә генә үзен алыштырып торуны сораган иде. Эш шартларын ошаттым да шушында калдым. Инде бирегә килүемә дә өч ел булды. Миңа кыр корабын иярләү күбрәк ошый, трактор күңелемә бик якын түгел. Урып-җыю вакытын түземсезлек белән көтеп алабыз. Шул көннәр җитүгә, йөрәк ешрак тибә башлый, күңел кырга ашкына. Берләән, иген кыры сагындырса, икенчедән, ярыш, азарт дәрте уяна. Хезмәт хакларыннан канәгать, тик бер теләк бар: яхшы комбайнчыларны билгеләгәндә барысына да бертөрле эш шартлары тудырылсын иде, – диде Рөстәм.

Кырлардан кайткан ашлыкны үлчәп, ындыр табагына озатучы Ания Сафина да озак еллар һөнәренә тугрылык саклый.

– Элеккеге еллар белән чагыштырганда, эшләү шартлары җир белән күк арасы кебек. Эшли торган биналарыбыз якты, матур. Ашлык электрон үлчәү аша уза, компьютер – төп ярдәмчебез. Хезмәт хаклары да, җитәкчеләр дә яхшы. Үзгәрешләр хәтта ашлык күләмендә дә сизелә. Колхозлар заманында гектарыннан 18–19 центнер ашлык җыеп алсак, бик куана идек. Хәзер гектарыннан зур күләмдә уңыш алып эшлибез. Тумышыбыз, бар булмышыбыз белән авылдан булгач, авыл хуҗалыгы – күңелебезне биреп эшләгән өлкә. Комбайнчылар сезонны ничек көтеп ала, без дә шулай ук ашкынабыз, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«Туган як» агрофирмасы директоры Раил ҖИҺАНГИРОВ:
– Быел сыналдык, әмма сынатмадык, чөнки эшләрне вакытында эшләп чыгу өчен һәркем тырышты. Кырау сугып, басуларга кабаттан бөртек чәчәргә туры килде. Нигезебез яхшы иде: туфракка ашламалар мулдан кертелде, техниканы да әзерләдек. Республика буенча караганда, иң алдынгы хуҗалык димәсәк тә, үзебезгә җитәрлек ашлык әзерли алдык. Ике ел рәттән безнең алда «Чаллы икмәге» җәмгыяте өчен бодай, арыш җитештерү бурычы тора. Без быел да өченче класслы бодай белән тулысынча тәэмин итәрлек ашлык әзерли алдык. Шул ук вакытта инде киләсе елга максатлар куеп эшлибез. Техниканы да яңартасыбыз килә. Инвесторларыбыз Рафаэль һәм Эдуард Юнысовларга рәхмәт. Алар быел 125 млн сум инвестиция кертеп, эш шартларын яңарттылар, егетләребезгә шәһәрдән ким булмаган яшәү шартлары тудырдылар. Бүген агрофирмада 46 механизатор эшли. Аларның уртача хезмәт хакы – 65 мең сум.

«Чаллы икмәге» җәмгыяте генераль директоры Эдуард ЮНЫСОВ:
– «Туган як» агрофирмасы – үзләрен 3 нче класслы ашлык белән тулысынча тәэмин итүче бердәнбер оешма. Эшчеләренә уңайлы булсын өчен яңа офис төзеделәр, авылны үстерү, аның киләчәге өчен тырышалар, яңалыкка омтылалар. Быелгы Уңыш бәйрәмен яңа форматта – гаиләләр өчен Сабан туе формасында уздырулары да – моңа дәлил.

БОХАРАЕВ ЗӨФӘР ГАРИФ УЛЫ
(07.04.1945 – 08.10.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Татарстан Республикасы элекке Кинематография буенча дәүләт комитеты рәисе Зөфәр Гариф улы Бохараев 8 октябрьдә 79 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Зөфәр Бохараев 1945 елның 7 апрелендә Казан шәһәрендә туган. 1969 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаган.

Хезмәт эшчәнлеген 1968 елда ВЛКСМның Казан шәһәре Бауман районы комитеты секретаре вазыйфасында башлап җибәргән. 1972 елда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетына эшкә күчерелгән.

Зөфәр Гариф улы 1979 елдан унбиш ел дәвамында Казан яшьләр үзәгенә җитәкчелек итте. Аның башлангычында Татарстан башкаласында яшьләр иҗатының төрле юнәлешләре буенча клублар челтәре булдырылды. 1994 елда исә «Казан Кремле» республика хәйрия фонды җитәкчесе итеп билгеләнде.

Зөфәр Бохараев 1995 елдан 2001 елга кадәр – Татарстан Республикасы Кинематография буенча дәүләт комитеты рәисе, 2001 елдан 2005 елга кадәр Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары вазыйфасын биләде.

Аның тырышлыгы белән республикада кино өлкәсе сакланып калу гына түгел, аны үстерүгә яңа этәргеч тә бирелде. Татарстанның кино елъязмаларын һәм күренекле мәдәният эшлеклеләре турында документаль кино төшерү яңартылды, татар телендә тулы метражлы тәүге нәфис фильм төшерелде, авылларда кино күрсәтү җиһазлары яңартылды. Зөфәр Гариф улы Казан халыкара мөселман киносы фестивален башлап җибәрүчеләрнең берсе булды.

Зөфәр Бохараевның эшчәнлеге Татарстан киноиндустриясен үстерүдә кабатланмас эз калдырды. Ул һәрвакыт иҗтимагый бурычка тугрылык хисе, эшенә иҗади каравы, профессионализмы, кешеләргә карата игътибарлы, ихтирамлы мөгамәләсе белән аерылып торды.

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» һәм «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медальләре, Татарстан Республикасының Мактау грамоталары, «Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре», Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәтләре.

Зөфәр Гариф улы Бохараевның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, И.Х. ӘЮПОВА, И.Р. МЕТШИН

Йөрәк эше

Ватан хакына

Ватанын сакларга карар кылган ир-атны берни дә туктата алмый! Махсус хәрби операциядә Грек позывное алган кыю егет шулай дип саный. Һавадан алып әйтелгән сүзләр түгел бу. Грек үзе армиядә хезмәт итмәгән, кулына утлы корал тотып та карамаган. Әмма ил-көнгә зур сынау килгәч, иң беренчеләрдән булып Ватанны сакларга чыгып киткән.

– Апамның ире махсус хәрби операция зонасында «Тимер» батальонында хезмәт итә. Минем дә алар сафына басасым килде. Абый бу уемнан кире кайтарырга тырышты, шактый үгетләде. Әмма мин үз дигәнемдә нык тордым. Коралны ничек кулланасын да белми идем бит. Өйрәнүләр вакытында барысына да төшендем, – дип сөйли егет «Татар-информ» хәбәрчесенә.

Шундый кыю карар кабул итүенә бүген дә сөенеп туя алмый егет. Бигрәк тә иң көчлеләрдән саналган «Тимер» батальонына эләгүенә шатлана.

– Безнең тугызынчы рота иң көчле һәм кыюлардан санала. Безнең турында һәркем ишетеп белә, башка бүлекчәләрдә хезмәт иткән егетләр дә безне әллә кайдан таный. Дошман белән күп дигәндә 20–30 метр гына аралыктан күзгә-күз очрашкан чаклар булды. Бик куркыныч, билгеле. Әмма атыш вакытында беребез дә чигенмәде – ахыргача сафта тордык. Ул аяусыз бәрелешләрдә күп егетләребезне югалттык, – ди Грек.

Ул яшерми: яу кырында иптәшләреңне югалтудан да кыенрак нәрсә юк. Махсус хәрби операциядә катнашу дәверендә Грекка андый аяныч күренешләр белән шактый очрашырга туры килә. Соңгысы Работино бистәсендә тукталган чакларында була.

– Тавышсыз гына очып килгән мина безнең ротадагы бер егетнең аяк астында ук шартлады. Ут янып торган егетебез бер мизгелдә юк булды. Тамакка төер тыгылды, күзләрдән туктаусыз яшь акты. Шундый шат күңелле егет иде, бернидән дә куркып тормады, гел алгы сафта йөрде. Аны югалткач, күңелгә ничек авыр булганын сүз белән генә әйтеп аңлатып бетерә торган түгел, – дип искә алды ул көнне Грек.

Әмма яу кырында озаклап елап-сыктап утырырга вакыт юк. Нинди генә зур хәсрәт-югалтулар кичерергә туры килсә дә, егетләр изге бурычларын үтәвен дәвам итә. Грек сүзләренә караганда, батальондагы егетләр бик бердәм. Төрле низаг-бәхәсләргә дә урын юк биредә.

«Татар-информ»

– Без тыныч тормышта яшәгән халкыбыз, балаларыбызның гомере өзелмәсен өчен көрәшәбез. Монда һәр егет – герой. Без һәрчак Ватан турында уйлыйбыз һәм Ватаныбыз да безне онытмас дип өметләнәбез, – ди Грек.

Өмет дигәннән, кыю егетнең күңелен җылытып, рух ныклыгы өстәп торган бер шатлыгы да бар. Бик тиздән ул әти булачак. Грек махсус хәрби операциягә китәр алдыннан гына өйләнгән. Әзерлек узганда исә тиздән әти булачагын белгән.

– Көтеп алган сабыебызның кызмы-малаймы икәнен бик тиздән беләчәкбез. Үзем кыз булсын иде дип хыялланам. Юкса безнең гаиләдә малайлар гына туа, – дип елмая кыю егет.

Грекның гына түгел, «Тимер» батальонындагы һәр егетнең әнә шундый күңел түрендә йөрткән зур өмет-маягы бар. Ватан сагында торганда сынмаска-сыгылмаска өнди, җиңүгә таба барырга көч өсти ул.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Өлкәннәр ункөнлеге

101 ЯШЬЛЕК ӘМИНӘ ЗАРИПОВА:
«МИННӘН ДӘ БӘХЕТЛЕ КЕШЕ ЮК»

Картлык. Һәркем аның матур, рәхәт булуын, балалар игелегендә, якыннары янәшәсендә узуын телидер. Балтач районының Түнтәр авылында гомер итүче Әминә Зарипова кебек. Аның хакында миңа авылдашлары: «Әминә әби кебек нурлы кеше башка юк бездә», – ди.

Әминә әбинең авылда чын исемен белмиләр дә. Нина исемле чуаш кызы татар авылына эшкә килеп, Балтачның табигатенә, кешеләренә гашыйк була. Насыйп яры – Закирын да шушы авылда очрата ул.

– Әниебез – Буа районының Әлши авылы кызы. Үзләрендәге фельдшерлар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Чепья районына эшкә җибәрелә. Аннары аны Арбор балалар бакчасына шәфкать туташы итеп эшкә билгелиләр. Соңрак Борнакта да эшли, – дип сөйли кызы Рәйхана. – Түнтәргә эшкә килгәндә, татар телен тәмам үзләштергән була инде. Әтием бер күрүдә ярата әнине. Биш вакыт намазын укыган бабай да каршы килми. Барысы да әнине үз итәләр.

Нина, исемен алыштырып, ислам динен кабул итә һәм кияүгә чыга. Закир абый белән бик матур яши алар. Биш бала үстерәләр. Олы уллары Шамил архитектура өлкәсен сайлый. Казанда укуын тәмамлагач, аны Ижевскига эшкә җибәрәләр. Кызганыч, пенсиягә чыгарга 3 ай кала яман шештән вафат була.

– Ижевск зоопаркын күргәнегез бардыр инде. Анда абыемның хезмәте зур. Шундый матур бина төзелешенә үз өлешен кертүе – барыбыз өчен дә горурлык. Нишлисең, гомере озын булмады. Еллар узса да, истән чыкканы юк. Абый гел янәшәдә кебек, – ди Рәйхана апа.

Икенче балалары Камил Тәтештә яши. Кызлары Рәйхана белән Рәсимә – Түнтәр авылында, кечеләре Рәсилә, абыйсы янына китеп, Ижевск шәһәрендә төпләнә.

– Әниебез һәр авырлыкны уздыра белде. Нинди генә хәл булмасын, ул аны сабырлык белән кабул итте. Чәүчәләнеп, бар дөньяга тавышланмады. Шулкадәр тырыш, эшчән ул. Эш белән яшәгез, гайбәткә вакыт калдырмагыз, дип әйтә иде. Кешедән көнләшмәде, безне дә шуңа өйрәтте, – ди Рәйхана апа.

Закир абый 93 яшендә бакыйлыкка күчә. Аның да тормыш юлы гыйбрәтле. Ике ел армия хезмәтеннән соң Бөек Ватан сугышы башлана. Рәйхана апа әтисе белән әнисенең бер сүздән аңлашып, бер-берсен яратып яшәвен сокланып сөйли:

– Син әйбәткә – мин әйбәт, мин әйбәткә – син әйбәт, диярләр иде алар. Тату яшәү гомерләрен озайткандыр да әле. Картлыклары да бергә үтте. Кайчак әниебез, озак яшәдем инде, дип тә куя. Тик без аны бик тиз юатабыз. Ул бит безгә бик кирәк, – ди Рәйхана апа. – Әнине юк-бар белән борчымыйбыз. Илдәге хәлләрне сөйләмибез. Начар хәбәр җиткермибез. Авыруларыбыз да бар. Берсен дә әни белми. Без аның янында гел матур, җылы итеп кенә сөйләшәбез. Әнине саклап кына торабыз.

Әминә әби Рәсимә кызы һәм кияве Васыйл белән бергә яши. Рәйхана апа да әниләреннән ерак тормый. Күрше йортта гына яшим, ди. Әни янына кереп чыккач, рәхәтләнеп китәм, ди ул.

– Әни, нәрсә пешерсәң, шуны ашый. Ризык талымламый. Элек, башта – ир, аннары балалар тук булсын дип, кешедән артып калганны гына ашый иде. Диета да сакламый. Майлы итләрне дә яратып ашап куя. Табигый ризык ашарга кирәк, кибет ризыгына ияләшмәсәң, чирләрең аз була, дип, безнең колакка киртләп куярга да онытмый, – ди Рәйхана апа.

Әниле тормыш – бөтенләй башка инде ул. 66 яшемдә дә «әни» дип эндәшә алуыма сөенәм, ди бит әнә Әминә апаның кызы да. «Әни дә, без дә, миннән дә бәхетле кеше юк, дибез. Әни янында шундый рәхәт. Гомер буена балаларга да, башкаларга да бик йомшак булды ул, – ди кызы Рәйхана. – Түнтәр халкына да рәхмәт! Әнине үз иттеләр, шуңа да бәхетле оя кора алганнар инде алар».

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Мач әйткән!

Эльчин СӘФӘРЛИ, азәрбайҗан язучысы:

– Балачактан олы тормышка бер генә әйберне алырга онытмаска кирәк – хыялны!

«Үпкәсез туй»

УЛ ТУЙНЫ МИН МӘҢГЕ ОНЫТМАМ!

ТНВ телеканалы алып баручысы Ландыш Хөсәенова кызыклы хатирәсе белән уртаклашты. Җәйге матур бер көнне табигать кочагында чираттагы бәхетле парны теркиләр. Кинәт кенә көчле җил чыгып, балдаклар салынган тартма җиргә төшеп китә, балдаклар чирәм арасына тәгәри. «Йөрәгем «жу» итте, – ди Ландыш. – Нишләргә? Ике секунд эчендә үземне кулга алдым да тантаналы чыгышымны дәвам итеп: «Ә хәзер кунаклар арасында квест тәкъдим итәм! Балдакларны кем беренче таба, шул яшьләргә чын күңелдән бәхет тели булып чыга!» – дидем». Уенны ди-джей да тиз генә «эләктереп» ала, дәртле музыка куеп җибәрә. Йөзләренә елмаю кунган кунаклар «уен»га кушылып, мәш килеп, балдак эзли башлыйлар. «Ул мизгелдә нәрсә кичергәнемне үзем генә беләм, – ди Ландыш. – Тартманы җил тәгәрәтте дә бит, алып баручы булгач, мин җаваплы лабаса!» Кияүнең әтисе бик җитез һәм үткер күзле булып чыга: иң беренче булып балдакларны ул таба. «Әлбәттә, һәр әти-әни баласына бәхет кенә тели, без моңа бүген тагын бер кат инандык!» – дип, Ландыш тантананы дәвам итә. Шөкер, яшьләр үзләре бу хәлгә артык игътибар бирмәгән, елмаеп кына кабул иткәннәр.

Акча бездә бер букча

Игътираз икътисад

Пенсия фондына бөтен кеше акча кертә. Ә чыгаруын исән калганнар гына чыгара ала.

***

«Аны акча бозды» дисеннәр иде әле минем турында да!

***

Доллар үсте – бәяләр үсте. Сум үсте – бәяләр үсте.

***

– Балаларың нихәл?
– Әйбәт. Берсендә – «Айпад», икенчесендә – «Айфон». Миндә «Айсаен»...
– Нинди «Айсаен»?
– Ай саен кредит.

***

Туганнар «Ватсап»ка открытка җибәргәнче, акча җибәрсеннәр иде.

***

Россия икътисадында бар да алдан уйланылганча, очраклы килеп чыкты.

***

– Син шундый төз гәүдәле! Диетадамы?
– Зарплатада.

***

– Робин Гуд ни өчен байларның гына акчасын алган?
– Хәерчеләрнең акчасы юк чөнки.

***

– Синең мотивация нинди?
– Мин мактанырга яратам. Ә моның өчен ниндидер уңышка ирешү кирәк.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Хатирә

БУХГАЛТЕР

Атаклы «Саз» ансамбле Бөтенсоюз күләмендәге лауреат исеменә лаек булган чак. Мин – «Кинопленка» клубында директор урынбасары, ә ансамбльнең җитәкчесе Рифкать Гомәров – минем шеф. Урынбасар булгач, җырдан тыш мәшәкатьләрне дә миңа тапшырдылар: ансамбльнең һәрбер җырчысы өчен юл, ашау-эчү, кунү-тору, акча чыгымнарын минем өскә йөкләделәр. Менә Мәскәүдә биек үрләр яулап, киерелеп, Казанга кайттык. Тегендә шимбә, якшәмбе көннәре туры килү сәбәпле, командировочныйларга печать сугар кеше таба алмадык. «Һәй, – диделәр, – мондый дәрәҗәләргә ирешкәч, кем сездән печать сорап торсын! Телевизордан да күрсәттеләр бит!»

Менә, кайткач, хисап ясап йөрим. Профком бухгалтеры Роза апа – урысча сөйләшүче безнеке шикелле – карап-карап торды да: «Пичәт бит ниту», – диде. Әйе, мәйтәм, печать сuктыра алмадык, чөнки ял көннәре туры килде. Мин бит инде шуны суктырыр өчен тагын ике көнгә кала алмыйм. «Чыгыш ясаганыгызны, лауреат булганыгызны бөтен ил күрде, шуңа күрә печать сорап тормаслар әле», – диделәр.

– Күрдегезме, Роза апа?
– Күрдем.
– Соң, шулай булгач, отчетымны кабул итеп алыгыз!
– Пичәт бит ниту...
Мин яңадан аңлатам:
– Без булдыкмы? Булдык. Генсек Брежнев кул чабып утырганын күрдегезме?
– Күрдем.
– Без лауреат булдыкмы?
– Булдыгыз.
– Соң, болай булгач, безнең Мәскәүдә булуыбыз сезгә мәгълүмме?
– Мәгълүм.
– Отчетны алыгыз!
– Пичәт бит ниту.
Мин яңадан башлыйм:
– Роза апа! Сез – кешеме, юкмы?
– Кеше.
– Алай булгач, алыгыз!
– Җә, ярый, калдыр инде.
– Рәхмәт.

Җиңеләеп, иңемнән тау төшкән кебек, клубка кайтып китәм. Рифкатькә, ниһаять, отчет ясадым, дип мактанып утыра идем, телефон шылтырый, Роза апа тавышы:
– Алмаз, пичәт бит ниту.
Ах, сүгендерәсез инде...

Алмаз ХӘМЗИН

Мәхәббәт өчпочмагы

– Әйдә, бүген кинога барабыз.
– Минем егетем бар.
– Аны да алыйк. Әмма билет өчен үзе түләсен.

***

Кияүдә булмаганнар кияүдә булганнарга кызыга. Кияүдә булганнар – кияүдә булмаганнарга. Һәм бары тик аерылганнар гына берәүгә дә кызыкмый.

***

– Ике сөяркәң булу турында ник алдан әйтмәдең?
– Оялдым.

***

– Матурым, мин – синең бердәнбер мәхәббәтеңме?
– Әлбәттә. Икәү булсагыз, егылып үләр идем.

***

– Хатыным белән барысын яңадан башлап карарга булдык.
– Һәм?
– Свиданиегә килмәде.

***

– Матурым, мин ял итәргә киттем. Озак торсам, улыбыз медицинскийга укырга керсен.

***

Ябык кызларны урлау җиңелрәк. Аша!

Шаян поэма

Кем гаепле?



Урманның уртасында
Җанварлар акчасына
Зур бер сарай салганнар,
Тик ачканда ватканнар...
Менә хәзер бирегә
Бар эшне тикшерергә,
Гаеплене табарга,
Хатаны ачыкларга,
Иң мөһиме, акчаны
Ничек кенә акларга...
Җыелганнар хайваннар
Гадел хөкем кылырга.

Иң түрдә аю абзый,
Аптырап, борын казый.
Алдындагы кәгазьдән
Аның миләре кайный...
Сәер тынлыкны бозып,
Аюга сырпаланып,
Сүз ала юха елан,
Отчетлар анда булган:
– Сездән җыйган акчага
Дәүләтебез кушканча,
Тендер аша уйнатып,
Төзүчене юлладык.

– Шунсын әйтергә кирәк:
Андый төзүче сирәк.
Сикереп чыкты күсе,
Сукыр тычканны сөйрәп.
– Миңа салган өйләре
Күргәзмәдәй үзләре,
Аның яңача караш
Таң калдырды күпләрне.
– Офталыгы тиңфеф, – дип
Йомран фы-фылдады.
Тик ябалак күргәнче
Өненә кереп шылды.
Һәр нәрсәне сырлаган
Саескан сизми калды.
– Җәмәгать, сез нишлисез?
Суд тәртибен белмисез?
Сүз әйткәнче иң элек
Теркәп куярга кирәк.
Аңлагыз, мин – сәркатип,
Булырга тиеш тәртип.
«Хуш», – дип пошкырды пошый,
Мөгезен болгый-болгый.
– Гаеплене тиз табыйк,
Сөзеп салыйк та таптыйк...

Китте бәхәс, китте шау,
Көр тавышлар чыкты дәү...

Туган туганын яклап,
Сват, братын саклап,
Шактый бәхәсләр купты,
Бик күп хаталар чыкты...
Тикшерелде чималлар,
Аны ташыган маллар,
Җир казыган тычканнар,
Кирпеч өйгән
куяннар,
Түбә япкан
торналар,
Тәрәз куйган чуртаннар,
Сызым сызган каргалар,
Сактагы ярканатлар...
Һәрберсе дә сүз алды,
Сәбәбен тезеп салды.
Нәрсә генә булса да,
Гаепле табылмады.

Сүз бирделәр прорабка –
Сукыр тычкан, батракка.
– Ипи тотып ант итәм,
Эшләдек намус белән.
Тик бер көн иртә таңнан
Песнәк дигән бер «шалкан»
Кунды да зур юкәгә
Шом салды йөрәкләргә.
«Сез мине кичерегез,
Ялгышсам, төзәтегез.
Киңәш итеп әйтүем,
Югарыдан күргәнем...
Нигезегез кәкере,
Бераз гына бөкере.
Сызгансыз чалышырак,
Туры казырга кирәк...»
Ә без нәрсә? Тыңладык,
Ул әйткәнчә кыландык.
Әмма песнәк киткәнен
Һич тә сизмичә калдык.
Гаеп – аны тыңлауда,
Ул бит башны бутады.
Җавап сүзе булмады,
Песнәк бит табылмады.
Җыелышка килмәде,
Авырып, өйдә калды.
Аю, урыныннан торып,
Акыллы сүз башлады.
– Дуслар, тавышка куям,
Песнәк гаепле булган!..
Сүзем бер: кыйнамыйбыз,
Мәрхәмәтле булабыз.
Тик сарайның акчасын
Казнага ул кайтарсын...
Шунысын өстәп әйтәм:
Белмәсә, өйрәтмәсен!
Сабак булсын гомергә.
Процентын түләр безгә.
Бар да кул күтәрделәр,
Тавышларын бирделәр...
«Әл дә коры чыктым», – дип
Шатланышып көлделәр.
...
Менә шулай, дускаем,
Гаепләләр күп җирдә,
Гаепсезләр интегә...

Илфак ХАФИЗОВ

Мәхәббәт шушыдыр, шушыдыр...

Ир вә хатын

– Безнең мөнәсәбәтләр бик җитди. Ул мине инде сторисында күрсәтте.

♡♡♡

– Хатын, мин төнлә гырласам, миңа төртмә. Гырлау ритмым бозыла һәм яңадан башларга туры килә.

♡♡♡

– Туйдан соң тёща безгә бер генә тапкыр килде.
– О! Син бәхетле.
– ...һәм китмәде.

♡♡♡

Минем ирем машинаның кайсы җире ватылган икәнен тавышыннан ук аңлый. Ә минем йөземнән үпкәләгән икәнлегемне аңлый алмый.

♡♡♡

18 яшьтә бала тапкан булсам, бүген инде савыт-саба юар кешем булыр иде.

♡♡♡

– Әни, Руслан миңа «син – бик әйбәт кыз» дип әйтте. Аны кунакка чакырыйм әле?
– Юк. Алга таба да шулай уйлавын дәвам итсен.

♡♡♡

Егетем белән өйләнешми яшибез. Туй турында ничек ишарә ясарга белмим. Бүген фата киеп, аш пешердем.

♡♡♡

Бензинга экономия йөзеннән ул хатынының әнисен бакчага шимбә көнне илтә иде, ноябрьдә алып кайта иде.

Авырмагыз!

ТАБИБ БҮЛМӘСЕНДӘ

– Доктор, минем никтер тешләрем саргая.
– Көз җитте бит.

⌄⌄⌄

Сезне сау-сәламәт дип уйлаучы бердәнбер табиб военкоматта эшли.

⌄⌄⌄

– Доктор, дәвалау ысулларын интернеттан карасам ярыймы?
– Үз-үзегезне дәвалауны ташлагыз, хәзер үзем «Гугл»ны актарам.

⌄⌄⌄

Нинди генә илгә күченеп китсәң дә, ел саен тешеңне дәваларга кайта торган туган җиреңне онытма.

⌄⌄⌄

Табиб янына бик бетерешкән ханым килә.
– Абау! Нәрсә булды сезгә?
– Мине ирем кыйный.
– Аңлашылды. Ромашка төнәтмәсе ясап, кич саен тамагыгызны чайкагыз.
– Бу гына ярдәм итәрме соң, доктор?
– Бик күпләргә ярдәм итте.
Бер атнадан ханым табиб янына кабат килә. Яшәреп, матураеп киткән:
– Бик зур рәхмәт инде сезгә, проблема хәл ителде, ромашканың файдасы бар икән!
– Ничек булмасын инде, кич буе тамак чайкап, ирегезгә бер сүз әйтә алмагансыз бит.

⌄⌄⌄

Медицина институтын тәмамлагач, мин:
1) һәрвакыт кулларымны юам;
2) балаларның ничек барлыкка килгәнен беләм;
3) бу дөньяда аппетитымны бетерерлек бернәрсә дә юк икәнен аңлыйм;
4) бергә укыган табиблар кулына эләгүдән куркам.

⌄⌄⌄

Психиатриядә халатны кем беренче кия – шул табиб.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 339

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+